РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

«_29_» _октябрь__ 2020 ел №_8__

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2018 елның 24 апрелендәге 149 номерлы «Җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү күләме нормативлары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 6 августындагы 658 номерлы «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең айлык акчалата түләүләре һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында» карары нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2018 елның 24 апрелендәге 149 номерлы «Җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы муниципаль предприятиеләре һәм учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт

өчен түләү күләме нормативлары турында» карарының 1 өлешендәге 3 абзацын бәян итәргә:

1.1. «Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладының күләме 11 498 сум тәшкил итә»;

1.2. «2нче кушымта «Муниципаль районда үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль район башлыгының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль районның Контроль-хисап палатасы Рәисенең акчалата бүләкләре күләмнәре» яңа редакциядә бәян итәргә, кушымта нигезендә.

2. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

4. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2020 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Муниципаль район
Башлыгы, Совет рәисе Ф.М. Дәүләтшин

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2020 елның 29 октябрендәге 8 номерлы карарына кушымта

2 нче кушымта
Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2018 елның 24 апрелендәге 149 номерлы карарына

Муниципаль районда үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль район башлыгының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль районның Контроль-хисап палатасы рәисенең акчалата бүләкләре күләмнәре

| Вазыйфаларның атамалары | Акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Башлык | 30442 |
| Башлык урынбасары | 27398 |
| Депутатлар | 14927 |
| Җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзалары | 12683 |
| Контроль-хисап палатасы рәисе | 27398 |

Район башлыгы урынбасары, район
Советы рәисе урынбасары Г.М. Җамалетдинов

Районы Советы аппараты җитәкчесе Ф.Ф. Камалов